**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2020 № 147

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү" муниципаль программасын раслау турында" 2015 елның 25 ноябрендәге 460 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү" муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 25 ноябрендәге 460 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Программа атамасында "2016-2020” саннарын "2016-2024" санына алмаштырырга»

1.2.Программа паспортында:

а) «Гамәлгә ашыру сроклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Гамәлгә ашыру вакыты | 2016-2024 еллар» |

б) «Программаның финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2016-2024 елларга Программаны финанслау күләме 15294 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
2016 ел-984,7 мең сум
2017 ел-1309,5 мең сум
2018 ел-1560,4 мең сум
2019 ел-1462,3 мең сум
2020 ел-1793,2 мең сум
2021 ел-1850,6 мең сум;
2022 ел -1913,4 мең сум;
2023 ел-2104,7 мең сум;
2024 ел-2315,2 мең сум;

Искәрмә: программаның финанслау күләме фаразланган характерда һәм район бюджеты акчаларының мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелеп торырга тиеш»

в) «Программаны гамәлгә ашыруның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары, максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр» бүлегенең егерме сигезенче абзацында «2016-2020 елгы» саннарын «2016-2024 елгы» саннарына алмаштырырга;

г) «ресурс белән тәэмин итүне нигезләү» бүлегендә икенче абзацта "5758,4 мең сум» санын “15294 мең сум” санына алмаштырырга»;

д) «Программаны гамәлгә ашырудан социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү» бүлегендә “2016-2020 еллар” санының икенче абзацында “2016-2024 елларга” саннарына алмаштырырга»;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Р.И. Галимовка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин